

Матбугат йортында регионыбыз хәрби коммисариаты вәкилләре, Мордовия Республикасы хәрби комиссары Игорь Валерьевич Тихомиров житәкчелегендә, брифинг vтте. Ул «Яз башы - 2018» темасын ачыклануга багышланды.
- Беренче апрельдән 18-27 яшьлекләрне чакыру компаниясе эшли башлады. Саранскта 2018 ел Ботендонья футбол чемпионаты vткәнгә, эшебезгә коррективлар кертелде: Россия Федерациясенен Кораллы Коче сафына хезмәткә чакыру саны азайтылды. Яз башы армиягә чакырылырга тиеш 600 яшvсмер (планны тутырдык) озатылды. Калганнары коз коне, беренче октябрьдә озатылачак, - ди Мордовия Республикасы хәрби комиссары Игорь Валерьевич Тихомиров. – Яналыкларга килгәндә, «2017елнын 29 декабреннән «О воинской обязанности и воинской службе» №444-ФЗ Федераль закон белән vзгәртvләр кертелгән.       Армия сафында хезмәт итәргә теләп тә, әлегә кадәр саулыклары буенча хәрби була алмаганнар, саулыгын 27 яшькә кадәр тозәткән егетләр, медицина тикшерve vтеп, солдатка алынырга хаклы. Шулай, яз башы призывында саулыгы начар булу белән бармый калган ике кеше, медицина освидетельсвованиесе vтеп, армиягә хәрби хезмәткә алындылар, ди хәрби комиссар. - ДОСААФ белән бергә 170 кеше машина йортvче һәм стрелок-парашютистлар әзерләп жибәрдек.
Санкт-Питербург белән Екатеринбугтагы фәнни ротага ун кешене юлладык. Ике призывник спорт ротасында хезмәт итә. Альтернатив хезмәт бик ук модада тvгел, әмма берәv Саратов олкәсендәге интернат йортта санитар булып хезмәт итә.
Тагы бер яналык. Беренче тапкыр 30 июньдә хәрби экипировка буенча акция vткәрдек. Алдагы елларда да vтәр дип уйлыйм».
Призывникларнын сәламәтлеге турында Виктор Александрович Якушкин, хәрбиләрнен саулыгын тикшерv комиссиясе рәисе, сойләде. Армиягә чакырылучыларнын, алдагы елларда тосле, аш казаны, эндокрин системасыһәм артык тазару авырулары хужалык итә дип әйтте.
Мордовиядә контракт буенча хезмәткә сайлау пункты житәкчесе Виктор Владимирович Валенцов болай дип сойләде: «Мордовиядән контракт нигезендә 2 ел хезмәт итvче бер кеше. Контракт хезмәтендәгеләргә тиешле социаль пакет исә офицерларныкы кебек vк; яшәv шартлары югары. Яналык - һәр атна А.С.Пушкин паркында экипировка кvргәзмәсе оештырабыз һәм патриотлар темасына кинофильмнар тvләvсез кvрсәтәбез. Чәй белән дә сыйлыйбыз. Рәхим итегез».
Хәрби хезмәттән качып йорvчеләр турында да сvз булды. Барысыннан бигрәк кvрше регионнарга эшкә китеп, бу турыда хәрби комиссариат бvлегенә хәбәр итмичә кыенлык

тудыралар. Быел «уклонистлар» саны - 700. Боларны юридик яктан «уклонистлар» дип әйтеп тә булмый,- ди Мордовия комиссары. - Чакыру комиссиясен vтеп чакыру алган, әмма чакыру пунктына килмәvчене шулай атыйлар.
Хәрби хезмәт vтv - һәр егетнен изге бурычы ул. Чын егет авырлыклар алдында куркып калмаска тиеш. Армиядән чыныгып, чын ир-егет булып, тормышны анларга, кыенлыкларны жинәргә өйрәнеп кайтканнарга кондәлек тормышта очраган проблемаларны чишv барыбер жинелрәк, дигән теләкне ишеттерде Мордовия хәрби комиссары.
Тагы журналистлар кызыксынып биргән сорауларга жаваплар алынды. Алар арасында безнен команда белән разведкага барыр идегезме дип И.В.Тихомировтан сорагач, «барыр идем!» дип жавап кайтарды.

**Наилә Насырова**